| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**21.10.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3971** |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының под-583/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 02 августындагы под-1381/24 боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктны әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. Нигезләмәнең «Стимуллаштыручы характерендагы түләүләр» V бүлегенең 3.3 пунктындагы унынчы абзацында «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калу һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе аермасы» билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе» сүзләрен өстәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә. .

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма комитетының
2024 елның 21 октябрендәге
3971 номерлы карарына кушымта

1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18405,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 18481,0<br>18550,0 |